Хәбибҗанова, Л. Скульптуралар яңа сулыш ала / Л. Хәбибҗанова // Шәһри Чаллы. – 2022. – №77 (21 октябрь). – Б. 3.

# Скульптуралар яңа сулыш ала

Төзек шәһәр

Лилия **Хәбибҗанова**

**Энтузистлар бульварында Чаллының бер төркем рәссамнары тарихи мирас – «Пробуждение» композициясе скульптураларын төзекләндерә.**

Аларны 1984 елда Чаллының танылган архитекторы һәм скульпторы Илдар Ханов ясаган. Бүген алар таушалган хәлдә. Кайбер элементлары купкан, төсен югалткан.

Объектта ТР Рәссамнар союзы әгъзалары эшли. Алар скульптураларның ташлары куптарылган урыннарына смальта ябыштыра. Эш барышын Татарстанның халык рәссамы, Россиянең атказанган рәссамы Владимир Акимов контрольдә тота. Яз көне ул ДОСААФ бинасындагы мозаиканы реставрацияләгән иде. Шәһәр мэры Наил Мәһдиев ул вакытта эшен югары бәяләде һәм Энтузиастлар бульвары скульптураларын тәртипкә китерүдә дә катнашырга чакырды.

«Композицияләрнең 20 проценты бөтенләй төсен югалткан. Без тиешле технологияләрне кулланып эшибез. Соңыннан акрил лак белән каплаячакбыз», – ди Владимир Акимов.

Белгечләр яңгырсыз көнне генә эшли ала. Ябыштырылган ташлар кимендә өч көн кибәргә тиеш. Әмма яшьләр комачаулый икән. Төзекләндерү эшләре баруын күрә торып, скульптуралар өстеннән сикереп йөриләр, смальталарны куптаралар дип борчыла рәссамнар.

Хәзерге вакытта «Пробуждение» композициясенең сигез скульптурасы төзекләндерелә. Аларны тәртипкә китерүдә шәһәр иганәчеләренең өлеше зур. Әйтик, бер эшмәкәр смальта сатып алуга 200 мең сум биргән.


© Лилия Хәбибҗанова фотосы